КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1032

Дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү тәртипләрен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен;

Дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 ноябрь, 1032 нче
карары белән расланды

**Дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм, дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр коммерциягә карамаган оешмаларның дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында бирелә.

3. Субсидияләр тиешле финанс елына субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсенә (алга таба – Идарә) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә.

Субсидия бирүне гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Идарә тора.

4. Субсидияләр субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә:

эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмаган;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокук актлары нигезендә акча алмаган.

5. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешмалар Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

Идарә тарафыннан расланган форма буенча субсидия алу өчен гариза;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документларының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен;

субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турындагы мәгълүматны;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган, финанс-икътисадый нигезләүне теркәп, бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасын;

килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның беренче көне хәленә карата Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең булмавын раслый торган салым органы белешмәсен;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган, коммерциягә карамаган оешманың килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның беренче көне хәленә карата үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмавы, шулай ук субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы турындагы гарантияле хатны.

Бу пунктның алтынчы абзацы белән күздә тотылган документны коммерциягә карамаган оешма тапшырмаган очракта, Идарә әлеге документны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

6. Субсидия алуга гаризалар кабул итү турындагы белдерү Идарәнең рәсми сайтында (http://zags.tatarstan.ru) бастырып чыгарыла. Белдерүдә Идарәнең документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе күрсәтелә. Коммерциягә карамаган оешмалардан субсидия алуга гаризалар бирү вакыты белдерү басылып чыккан көннән алып 10 календарь көн тәшкил итә.

7. Документлар кәгазь чыганакта тапшырыла. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен коммерциягә карамаган оешмалар законнар нигезендә җавап бирә.

8. Идарә гаризаны кергән көнендә теркәүгә ала һәм гаризаны теркәүгә алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Субсидия бирүгә гаризаларны бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегенең төп юнәлешләре бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларга туры килү;

дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру өчен матди-техник һәм кадрлар ресурслары булу;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендә, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруда тәкъдим ителә торган чараларның иҗади үзенчәлеге, икътисадый һәм социаль әһәмияте һәм актуальлеге;

гаиләнең һәм никахның традицион кыйммәтләрен популярлаштыру, дәүләт гаилә сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле проектны (программаны, материалларны) үстерү перспективалары.

Гаризалар һәр критерий буенча 5 баллы шкала буенча бәяләнә (1дән 5кә кадәр).

Субсидия гаризалары иң күп балл җыйган гариза бирүчеләргә бирелә. Шул ук вакытта субсидия алучыларның саны агымдагы елда субсидияләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре лимитларыннан чыгып билгеләнә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

бу Тәртипнең 5 нче пунктындагы икенче – бишенче, җиденче абзацлары белән күздә тотылган документларны тапшырмау (тулысынча тапшырмау);

бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау;

коммерциягә карамаган оешма бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Идарәгә билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

11. Идарә карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә язма рәвештә кабул ителгән субсидия бирү турындагы һәм субсидия бирүдән баш тарту турындагы карар хакында хәбәр итә.

12. Субсидия бирү Идарә һәм субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән коммерциягә карамаган оешма (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле булган чыгымнар төрләре;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре һәм аларның мәгънәләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидияләрдән файдалану турында, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар бирү вакытлары һәм формасы;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

Идарә тарафыннан субсидия өлешләрен файдалануда ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия өлешләре торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучыларның һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның Идарә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

югары технологияле чит ил җиһазларын, чималны һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, чит ил валютасының алынган акчасы исәбеннән сатып алуны тыю;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

13. Идарә килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 20 көн эчендә субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына бер тапкыр күчерә.

14. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарның юнәлешләре:

хезмәт өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алу;

командировка чыгымнары;

мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве;

физик һәм юридик затларның хезмәт күрсәтүләре өчен, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту һәм аларга бәйле булган башка хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

алга таба сату өчен билгеләнмәгән полиграфия, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу (әзерләү);

бу Тәртипнең 1 нче пункты белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу;

дәүләт гаилә сәясәте, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле проектны (программаны) тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган оештыру чыгымнары.

15. Субсидия күләме, шундый ук товарларның, эшләр башкаруның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан чыгып, түбәндәге формуланы кулланып билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + \ldots + З_n ,$$

монда:

С – субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$, … + $З_n$ – чаралар составына нигезләнгән һәм документлар белән расланган түбәндәгеләргә бәйле чыгымнар кертелә торган әлеге чыгымнарны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар:

хезмәт өчен түләүгә;

командировка чыгымнарына;

мөлкәттән файдалану өчен аренда түләвенә;

физик һәм юридик затларның хезмәт күрсәтүләре өчен, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре һәм аларга бәйле булган башка хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар түләүгә;

алга таба сату өчен билгеләнмәгән полиграфия, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алуга (әзерләүгә);

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алуга,

бу Тәртипнең 1 пункты белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алуга.

16. Субсидия алучылар субсидиядән файдалану турындагы, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны Идарәгә килешүдә каралган вакытлар һәм форма нигезендә кертә.

17. Идарә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидия алучыларга субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнар нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Субсидия Идарәнең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы һәм Идарә үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган;

субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган;

субсидиядән файдалану турындагы хисапны килешүдә билгеләнгән вакытта тапшырмаган;

субсидия чараларын максатчан файдаланмаган;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешмәгән.

19. Килешү белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия өлешләре субсидияләр алучы тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш. Идарә тарафыннан әлеге акчадан файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, алар финанслар белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган тиешле өлешләре булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыруга юнәлдерелергә мөмкин.

20. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 18 нче һәм 19 нчы пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылган очракта, Идарә субсидияне кире кайтару вакыты чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

21. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Идарә тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 ноябрь, 1032 нче
карары белән расланды

**Дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге, гаилә кыйммәтләрен популярлаштырудагы чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) (алга таба – субсидия) бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Субсидияләр коммерциягә карамаган оешмаларның дәүләт гаилә сәясәте өлкәсендәге, гаилә кыйммәтләрен популярлаштырудагы чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарын каплау максатларында бирелә.

3. Субсидия коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән тыш) тиешле финанс елына субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсенә (алга таба – Идарә) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә:

эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмаган;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокук актлары нигезендә акча алмаган.

5. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешмалар Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

Идарә тарафыннан расланган форма буенча субсидия алу өчен гариза;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документларының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен;

субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турындагы мәгълүматны;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасын;

коммерциягә карамаган оешманың фактта сарыф ителгән чыгымнарын раслый торган документлар (шартнамәләр һәм аларга кушымталар, түләү документлары (исәпләр, счет-фактуралар, түләү йөкләмәләре, керем һәм чыгым ордерлары), башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, йөкнамәләр һ.б.) күчермәләрен;

килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның беренче көне хәленә карата Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган, килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның беренче көне хәленә карата коммерциягә карамаган оешманың үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмавы, шулай ук субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы турындагы гарантияле хатны.

Бу пунктның җиденче абзацы белән каралган документны коммерциягә карамаган оешма тапшырмаган очракта, Идарә әлеге документны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

6. Документлар кәгазь чыганакта тапшырыла. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен коммерциягә карамаган оешмалар законнар нигезендә җавап бирә.

7. Идарә гаризаны кергән көнендә теркәүгә ала һәм гаризаны теркәүгә алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

8. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

бу Тәртипнең 5 нче пунктындагы икенче – алтынчы, сигезенче абзацлары белән күздә тотылган документларны тапшырмау (тулысынча тапшырмау);

бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау;

коммерциягә карамаган оешма бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Идарәгә билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

9. Идарә карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә язма рәвештә кабул ителгән субсидия бирү турындагы һәм субсидия бирүдән баш тарту турындагы карар хакында хәбәр итә.

10. Субсидия бирү Идарә һәм субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән коммерциягә карамаган оешма (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар төрләре;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре һәм аларның мәгънәләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидияләрдән файдалану турында, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар бирү вакытлары һәм формасы;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

субсидия алучының Идарә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

Идарә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча субсидияне максатчан файдаланмау һәм бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән шартларны бозу фактларын билгеләгән очракта, коммерциягә карамаган оешма тарафыннан файдаланылмаган суммаларны кире кайтару тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

11. Идарә килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 20 көн эчендә субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына бер тапкыр күчерә.

12. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарның юнәлешләре:

хезмәт өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алу;

командировка чыгымнары;

мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве;

физик һәм юридик затларның, шул исәптән элемтә, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту һәм аларга әйле башка хезмәтләр өчен түләү;

алга таба сату өчен билгеләнмәгән полиграфия, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу (әзерләү);

бу Тәртипнең 1 пункты белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу;

дәүләт гаилә сәясәте, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле проектны (программаны) тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган оештыру чыгымнары.

13. Субсидия күләме, шундый ук товарларның, эшләр башкаруның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан чыгып, түбәндәге формуланы кулланып билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + \ldots + З_n ,$$

монда:

С – субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$, … + $З_n$ – составына нигезләнгән һәм документаль засланган түбәндәгеләргә бәйле чыгымнар кертелә торган чараларны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар:

хезмәт өчен түләүгә;

командировка чыгымнарына;

мөлкәттән файдалану өчен аренда түләвенә;

физик һәм юридик затларның хезмәт күрсәтүләре өчен, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре һәм аларга бәйле булган башка хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар түләүгә;

алга таба сату өчен билгеләнмәгән полиграфия, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алуга (әзерләүгә);

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алуга,

бу Тәртипнең 1 пункты белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алуга.

14. Субсидия алучылар субсидиядән файдалану турындагы, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны Идарәгә килешүдә каралган вакытлар һәм форма нигезендә кертә.

15. Идарә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидия алучыларга субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнар нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

16. Субсидия Идарәнең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган;

субсидия бирү шартларын үтәмәгән;

субсидиядән файдалану турындагы хисапны килешүдә билгеләнгән вакытта тапшырмаган;

субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешмәгән.

17. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 16 нчы пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылган очракта, Идарә субсидияне кире кайтару вакыты чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

18. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Идарә тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

___